Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

11 октябрь, 2023 ел № 8

Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 141 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 35 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Күн авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Күн авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Күн авылында. Халык җыенын биш этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2023 елның 24 октябрендә 08.00 сәгатьтә Мәктәп урамы, 1 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яңа, Урман, Мәктәп, Кави Шакирова урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2023 елның 24 октябрендә 10.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамының йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2023 елның 25 октябрендә 08.00 сәгатьтә М.Конов урамы, 17 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә М.Конов урамы, Комсомол урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының дүртенче этабы 2023 елның 25 октябрендә 09.00 сәгатьтә Пионер урамы, 16 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Пионер урамы, Тукай урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының бишенче этабы 2023 елның 28 октябрендә 11.00 сәгатьтә Сосновая урамы буенча балалар мәйданчыгы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Алмаз, Вишневая, Ильдар Мархабин, Кедровая, Клубничная, Малиновая, Светлая, Солнечная, Сосновая, Счастливая, 3-я Строителей урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

«Сез, 2024 елда Күн торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, 90 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Кызыл Яшьләр авылында. 2023 елның 28 октябрендә 8.00 сәгатьтә Колхоз урамындагы 9 йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2024 елда Күн авыл җирлеге Кызыл Яшьләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, 90 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Әлбәдән авылында. Гражданнар җыенын 2023 елның 28 октябрендә 09.00 сәгать Күл буе урамы, 25а йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Әлбәдән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баһауов